ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

07.11.2019 г. Заинск №270

2030 елга кадәр перспективада Зәй шәһәрен су белән тәэмин итүнең һәм су бүлеп бирүнең актуальләштерелгән схемасын раслау турында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 2011 елны 07 декабрендә кабул ителгән 416-ФЗ номерлы Федераль законы, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү схемалары турында» 2013 елның 05 сентябрендә кабул ителгән 782 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә

карар бирәм:

1. 2030 елга кадәр перспективада Зәй шәһәрен су белән тәэмин итүнең һәм су бүлеп бирүнең актуальләштерелгән схемасын кушымта нигезендә расларга.
2. «2030 елга кадәр перспективада Зәй шәһәрен су белән тәэмин итүнең һәм су бүлеп бирүнең актуальләштерелгән схемасын раслау турында» Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башкарма комитетының 2018 елның 03 октябрендәге 229 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга һәм Зәй шәһәрен су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирүнең схемасын билгеләнгән тәртиптә Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе **А.В. Петров**